БЕЗНЕҢ ӨМЕТ

Рөстәм Миңнеханов илкүләм «Яшь профессионаллар – 2022» чемпионаты җиңүчеләре белән очрашты

> 2

СУЛЫКЛАР ПЫЧРАНА

Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы кайбер оешмаларга кисәтү ясады

> 2

ҖИРДӘГЕ ЭЗ

Баһавиевлар гаиләсенең нәсел җепләре

> 3

БУЛДЫКЛЫ ХАТЫН

Гөлсирә Сәйфуллинага 70 төрле һөнәр дә аз

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 154 (28927) | Чәршәмбе | 19 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЭШ БАТЫРЫННАН – ИЛ БАТЫРЫНА

ХЕЗМӘТ БАЗАРЫНДАГЫ ВАЗГЫЯТЬ

Өлешчә мобилизация хезмәт базарын да читләтеп узмады. Яңа шартларга яраклашырга мәҗбүр булган эш бирүчеләр һәм эш урыннарын калдырып, хәрби хезмәткә чакырылучылар өчен борчылырлык сәбәп бармы? Бүген хезмәт базарында вазгыять нинди? «ВТ» хәбәрчесе шуларны белеште.

Идар Мөхәммәтҗанов

Татарстан хезмәт базарында вакансияләр саны бер ай эчендә 1 меңгә арткан. Хәзер анда 75 меңгә якын вакансия бар. Ел башында бу сан 56 меңне тәшкил иткән.

Базардагы вазгыятьне белешү өчен, Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать иттек. Министрлыкның матбугат үзәгендә, хәзерге вакытта хезмәт базарында хәл тотрыклы, диделәр. Республикада эшсезлек дәрәҗәсе түбән. Татарстанда эшсезләр саны 9900 кешене тәшкил итә. Халыкның мәшгульлеге шактый югары – 62 проценттан артык. Ил буенча бу күрсәткеч – 59 процент. Республикада эшсез кешенең чагыштырма портреты мондыйрак – шәһәрдә яшәүче 40 яшьтән өлкәнрәк, урта яки төп гомуми белеме булган һәм, кагыйдә буларак, элек сәүдә өлкәсендә эшләгән хатын-кыз.

10 октябрьгә китерелгән саннарга караганда, «Россиядә эш» порталында төрле һөнәрләр буенча 75 мең буш урын тәкъдим ителә. Министр урынбасары Клара Таҗетдинова әйтүенчә, эшкәртү производствосы өлкәсендә, төзелеш, транспорт, файдалы казылмалар табу тармакларында эшләүчеләр арткан. Ә менә сәүдә, мәгариф, электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү, финанс һәм иминиятләштерү өлкәләрендә, киресенчә, кимегән. Киләчәктә эшкәртү сәнәгатендә, транспорт, элемтә тармакларында эшләүчеләр артачак.

– Вакансияләрнең мондый санда булуы эшче көчләр җитмәү турында сөйли. Кадрлар кытлыгы предприятиеләрне хезмәт базарында конкурентлыкка этәрә, хезмәткәрләрнең бәясен күтәрүгә китерә. Бу шартларда кадрларны тулыландыруның барлык чараларын күрергә кирәк, – диде Клара Таҗетдинова.

Хезмәт министрлыгы белгечләре оешмаларга һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар белән эшләргә, аларны практикага чакырырга тәкъдим итә.

– «Демография» милли проекты кысасында татарстанлыларны төрле белгечлекләр буенча укыталар. Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, экспортка ярдәм итү, кече бизнесны үстерү буенча илкүләм проектлар бирә торган мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк. Алар сәнәгатьтә, авыл хуҗалыгында һәм башка тармакларда көндәшлеккә сәләтле заманча предприятиеләр булдыру өчен кирәк, – диделәр матбугат үзәгендә.

hh.ru мәгълүматлары буенча, август белән чагыштырганда, административ персоналның, юристлар һәм чимал чыгару тармагы хезмәткәрләренең, пиар белгечләренең, укытучыларның, медицина, фармацевтика, югары менеджмент өлкәләрендә эшләүчеләрнең хезмәт хаклары арткан.

Республикага җитештерүчеләр, сәүдәгәрләр, төзүчеләр, электриклар, машина йөртүчеләр кирәк. Шулай ук укытучыларга, табибларга, азык-төлек сәнәгатендә эшләүчеләргә дә ихтыяҗ зур. Нигездә ир-атлар эшли торган җитештерү, транспорт һәм төзелеш өлкәләрендә кадрлар кытлыгы булырга мөмкин, ди белгечләр.

Мәгълүм булганча, мобилизация буенча чакырылган кеше белән хезмәт килешүе вакытлыча гына туктатылырга тиеш. Эш бирүченең хезмәт килешүен өзәргә яки әлеге гражданинны эштән җибәрергә хокукы юк. Хәрби хезмәт беткәч, өлешчә мобилизациягә чакырылган кеше элекке шартларда үз эш урынына кайтарылырга тиеш.

«Таттелеком» элемтә операторы мобилизациягә чакырылган хезмәткәрләренә һәм аларның гаиләләренә 100 мең сум түләячәк. «Кадрлар кытлыгы юк, мобилизацияләнгән ир-атларыбызны вакытлыча башка хезмәткәрләр белән алыштырып торабыз», – диделәр матбугат үзәгендә.

«Нәфис-Косметикс» предприятиесе илне сакларга киткән хезмәткәрләренә 30 мең сум түләячәк. Мобилизацияләнгән эшчеләре бар, тик күп түгел.

– Мобилизацияләнгән егетләребез алдында мөһим бурычлар торуын аңлыйбыз, шуңа аларга ярдәм итәргә булдык. Предприятиедә җитештерү эшендә өлешчә мобилизация чагылыш тапмады. Хезмәткәрләрнең күпләп эштән китү очраклары да юк. Барлык мобилизацияләнүчеләрнең дә эш урыннары сакланачак, – диде оешманың генераль директоры Динә Лаврикова.

Ахыры 2 нче биттә >

Бер квадрат метры – 54 мең сум

Татарстан авылларындагы йортларның бер квадрат метры күпме торуын расладылар. Бу эш республика районнарына 2023 елга субсидияләр күләмен исәпләү өчен башкарыла. Әлеге субсидия наем шартнамәсе буенча бирелә торган йорт төзегәндә яисә сатып алганда өстәмә финанс ярдәме буларак түләнә.

Шулай итеп, авыл йортының бер квадрат метры 54 мең сумны тәшкил итәчәк. Тиешле карарны Татарстанның Премьер-министры Алексей Песошин имзалаган.

Универсаль түләү

Дәүләт Думасы беренче укылышта йөкле хатыннарга һәм 17 яше тулмаган балаларга универсаль пособие түләү турындагы закон проектын кабул итте. Киләсе елның 1 гыйнварыннан әлеге пособие түләнә башланачак дип фаразлана.

Универсаль пособие берничә социаль түләүне үз эченә алачак. Аңа йөклелек башыннан ук исәпкә баскан өчен каралган түләү дә, балага 1,5 яшь тулганчы түләнә торган пособие дә, беренче бала өчен билгеләнгән акча да керә. Моннан тыш монда өченче баланы тапкан өчен каралган түләү дә (ул Россиянең 78 төбәгендә гамәлдә), башкалары да кергән.

Пособие бер кешенең кереме яшәү минимумыннан азрак булган гаиләләргә каралган. Әлеге пособиегә гаризаны дәүләт порталы аша, күпфункцияле үзәккә яисә Социаль иминият фондына барып язарга була.

Декада ничек узачак?

3 декабрьдә Халыкара инвалидлар көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан 1 декабрьдән алып 10 декабрьгә кадәр Татарстанда инвалидлар декадасы узачак. Татарстанның Премьер-министры Алексей Песошин чаралар планын 7 ноябрьгә кадәр эшләп тапшырып, расларга боерды.

Боерык документыннан күренгәнчә, Татарстанның Мәдәният министрлыгы Инвалидлар җәмгыятен республикадагы мәдәният учреждениеләренә чакыру билетлары белән тәэмин итәргә тиеш була. Шулай ук Татарстанда инвалидлар декадасы кысасында мөмкинлекләре чикле булган кешеләргә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, алар өчен каралган спорт объектларын тикшерү һәм спорт чаралары үткәрү, тарихи-мәдәни мирас объектлары буенча экскурсияләр, эш тәкъдим итүчеләр белән очрашу оештыру кебек чаралар көтелә. Моннан тыш, гаилә әгъзалары арасында мөмкинлекләре чикле кеше булган һәм исәптә торучы гаиләләрне торак белән тәэмин итү мәсьәләләренә игътибарны көчәйтергә тәкъдим ителде.

Шауласын урман

Агымдагы ел башыннан бирле Татарстан урманнары өчен 1,7 мең килограмм агач орлыгы әзерләнгән. Шуның 142 килограммын – чыршы, 761 килограммын – нарат, 25 килограммын – карагач, 20 килограммын – каен, 34 килограммын – юкә, 550 килограммын – имән, 202 килограммын башка төрдәге агач орлыгы тәшкил итә. Иң күп агач орлыгы Арча, Яшел Үзән һәм Саба районнарының урман хуҗалыкларында әзерләнгән. Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, быелга барлыгы 11455 килограмм агач орлыгы әзерләү күздә тотыла. Бу эш «Экология» илкүләм проектының «Урманнарны саклау» федераль проекты кысасында тормышка ашырылучы «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк проекты нигезендә башкарыла.

tatarstan.ru

Ярдәм янәшә!

Ялгыз калмаячаклар

Татарстанда өлешчә мобилизацияләнүчеләргә барлык өс-баш киемнәре, гомумән, бөтен кирәк-яраклар биреләчәк. Хәзерге вакытта ниләр кирәклеге ачыклана. Балалар исә матди ярдәм алачак. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган брифингта хәбәр иттеләр.

– Республика Президенты кушуы буенча, мобилизациягә эләккән һәр ир-ат кирәкле барлык кирәк-яраклар белән тәэмин ителәчәк, – диде Татарстанның Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева. – Интернеттагы һәр мөрәҗәгатьне, министрлыкларга һәм «кайнар линия»гә килгән сорауларның һәркайсын өйрәнәбез. Өлешчә мобилизациягә эләккән кешеләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү йөзеннән республикада 11 октябрьдән «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте үз эшен башлады. Без мондый чакта берләшергә тиеш. Ялгыз берни эшләп булмый.

Берләшү дигәннән, республиканың күп кенә оешмалары үзләренең бер көнлек хезмәт хакларын солдатларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен «Ак Барс Созидание» хәйрия фондына күчерә башлаган. Оешмалар гына түгел, хәтта пенсионерлар да акча алып киләләр икән. Җыелган акчаның барысы да егетләр өчен тотылачак. Аларның гаиләләре дә читтә калмый. Җитәкчеләр аңлатканча, инде хәзердән үк этиләре өлешчә мобилизацияләнгән сабыйларны мәктәпләрдә бушлай ашаталар, бакчага йөргән өчен түләтмиләр. Алар өчен түгәрәкләргә йөрү дә бушлай булачак.

18 яшькәчә балаларга бер тапкыр 20 мең сум акча да түләнәчәк. Бу хакта Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова хәбәр итте.

– Бу акча автомат рәвештә түләнми. Аны алыр өчен күп кенә мәгълүматны тикшерергә кирәк. Без өлешчә мобилизацияләнгән кешеләрнең гаиләләрен йөреп чыктык. Әгәр солдатның балалары бар икән, алар дәүләттән бирелә торган ярдәмгә өметләнә ала, – ди Эльмира Зарипова. – Өйгә килүчеләр гариза кәгазен калдырачак. Бу гаризаны күрсәтелгән вакытка тутырып, үз районыгызда урнашкан матди ярдәм күрсәтү үзәгенә илтеп тапшырырга кирәк. Үзегез белән паспорт, балагызның туу турындагы таныклыгын, акча күчерер өчен исәп-хисап счетларын алыгыз. Туу таныклыгында «әтисе» дигән урында мобилизацияләнгән ирнең исеме торырга тиеш. Хәрби комиссариаттан берничә белешмә дә кирәкми.

Район-авылларда бу хакта беләләр икән инде. Ә менә шәһәрләр белән эшләр бераз катлаулырак. Солдат әти теркәлгән урында гаиләнең яшәмәве дә ачыклана икән. Шуңа да Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә гаризаларны балалар бакчасы һәм мәктәпләр аша тапшырачаклар. Министр, киләсе атна башыннан сабыйларга 20 мең сум килә башлаячак, дип ышандырды. Әлеге акча үз теләге белән хәрби операциягә китүчеләргә кагылмый.

Ишетеп-күреп торабыз: мобилизация башлангач, өйләнешүчеләр һәм әти икәнлекләрен танучылар артты. Элек бергә яшәп тә, никахларын теркәмәгән кешеләр дә тизрәк ЗАГСка йөгергән. Ирләр моны якыннары дәүләт ярдәменнән мәхрүм калмасын өчен эшли, ди министр.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Дмитрий ПЕСКОВ, Россия Президентының матбугат үзәге башлыгы:

Мобилизация буенча биремнең үтәлүен төбәкләр үзләре хәбәр итә. Биремне үтәгән төбәкләрдә өлешчә мобилизация төгәлләнгән һәм туктатылган. Әлегә Владимир Путинның илдә өлешчә мобилизация тәмамлану турындагы Указы юк.

(«Интерфакс»)

РОССИЯДӘ – АЗЫК-ТӨЛЕК ҖИТЕШТЕРҮ

«Аргументы и факты» газетасы тәкъдим иткән мәгълүматларга караганда, Россиядә бер ел эчендә көнбагыш мае җитештерү 18 процентка арткан. Ә эремчек җитештерү, киресенчә, 7,4 процентка кимегән.

Көнбагыш мае	+18
Ярма	+12,6
Атланмай	+10,9
Макарон ризыклары	+10,2
Бодай оны	+7,2
Ит	+7,1
Җиләк-җимеш һәм яшелчә соклары	+4,8
Кош ите	+3,5
Сөт	+3,3
Сыр	+3,1

Каймак	-0,2
Колбаса ризыклары	-1,2
Икмәк-күмәч ризыклары	-2,7
Шоколад һәм баллы ризыклар	-2,9
Эшкәртелгән һәм консервланган бәрәңге	-4,5
Балык консервлары	-4,6
Шикәр	-6,4
Эремчек	-7,4

*процентларда



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АМЕРИКАН – ГАРӘП КАРШЫЛЫГЫ: КЕМ КЕМНЕ?

Россия – Украина конфликты (ул хәзер Россия – НАТО каршылыгына үсү фазасында) дөнья сәясәтендә уен карталарын тәмам бутап бетерде. Элекке аркадашлар бер-берсенә арттан пычак кадый башлады, элек күндәм генә Вашингтон диктатына буйсынган илләр аңа каршы чыгыш ясыйлар. ОПЕК+ картеленең нефть чыгаруны ноябрьдән башлап 2 миллион баррельгә киметү карары АКШның тәмам кытыгына тиде. Океан артындагы башкалада моны үзләренә ясалган һөҗүм дип аңлыйлар һәм картельнең башында торган Согуд Гарәбстанына төрлечә басым ясарга тырышалар. Эш шунда: нәкъ менә ноябрьдә Америка Сенатына сайлау үткәрелә. Сайлау алдыннан гына нефтькә бәяләр күтәрелү Байден администрациясенә бик каты суга. Демократлар партиясе сайлауда оттырса, хәзерге лидерның сәясәтен үткәрү кыенлашачак. Шуңа күрә Ак йорт гарәпләрдән нефть чыгаруны тагын бер генә ай булса да киметмәүләрен инәлеп сорады, тегеләр тыңламадылар. Лидерның абруена гына түгел, бөтен Демократик партиягә бик каты суга бу хәл. АКШ, NOPEC законы (нефть чыгару һәм экспортлауда картельләрне тыю) дигән законга таянып, гарәпләрне җавапка тартырга ниятли. Закон бар ул барлыкка, әмма аны куллана алганнары юк. Моңарчы сәбәбе дә бик булмады инде, гарәпләр гел американнар кубызына биеделәр. Хәзер вазгыять башка. Bloomberg (финанс мәгълүматы сатып акча эшләүче компания, без аның материалларын еш файдаланабыз), Ак йорт, NOPEC канунына таянып, суд процессы башласа, вазгыять бөтенләй фаҗигале рәвештә үзгәрергә мөмкин, ди. АКШ, әлбәттә, судта отар (үз суды бит), әмма ОПЕК+ нең иң йогынтылы иле булган Согуд Гарәбстаны, моңа җавап итеп, Американың финанс активларын сата башлар, бу фонд базарын җимерер, дип фаразлый. Аннан да куркынычрагы: гарәпләр долларга нефть сатуны туктатырлар, дип шикләнә. Әгәр шулай эшләсәләр, долларның көннәре санаулы.

Әйдәгез, хәзер рәсми хәбәрләрдән бераз читкә китәбез дә дилетантларча фикер йөртәбез. Гарәпләрнең нефть базарын киеренкелектә тотулары Россия өчен файдалы. Әмма аларны Россиягә мәхәббәттә гаепләү кыен. Әле генә аларның оборона министры: «Согуд Гарәбстанында «корольлек Украинага каршы сугышта Россиягә булыша» дигән гаепләүгә бик гаҗәпләнделәр», – дип белдерде. Шуның артыннан ук Әр-Рияд Киевка 400 миллион долларлык ярдәм дә вәгъдә итеп ташлады. Димәк, эш Мәскәүне сөюдә түгел, Вашингтонга мәхәббәт сүрелүдә. Гарәпләр бит күреп торалар: янкилар аз гына ачуландылармы, санкцияләр кертәләр дә алар белән финанс базарын уртаклашкан дәүләтләрне кычкыртып талыйлар. Бу инде аларга ышаныч юк икәнен раслый. Шуңа күрә акрын гына тәртәләрне борып, башка аркадашлар һәм мал саклау өчен башка активлар эзлиләр. Бу тартышуда субъектив момент та бар. Бөекбритания королевасының җеназасына баргач, Көнбатыш лидерлары Согуд принцы Мөхәммәд ибн Сәлмәнне журналист Җәмәл Хашоггины үтерүдә гаепләп мыскыл иттеләр, дипломатия тарихында күзәтелми торган эш эшләнде. Принц, җеназа төгәлләнгәнче үк, үпкәләп кайтып китте. Көнбатыш хәзер шул эшләрнең нәтиҗәсен татый.

Американнар, әлбәттә, гарәпләргә коралпы һөҗүм ясамаячаклар, әмма илне кыен хәлгә куеп, фетнә оештырырга тырышачаклар. Көтеп торыйк. Якын Көнчыгышта борылыш ясый алырлармы, юкмы?

Россиядә

КҮК КҮКРӘРМЕ, ӘЛЛӘ ФИНАНСЛАР ГЫНА ҖИМЕРЕЛЕРМЕ?

Россиядә атом-төш триадасы катнашында (коры җир, диңгез һәм һава көчләреннән торган өчлек) бу ел башыннан инде икенче тапкыр стратегик атом-төш коралларының сынавы үткәрелергә тора. Көнбатышның мәгълүмат кырында бу уңайдан «Путин атом сугышының башын репетицияли» дигән хәбәрләр күренә. Америка хәрби җитәкчелеге CNNга биргән интервьюда ул өйрәнүләрне «гадәттән тыш һәм көтелмәгән гамәлләр булмасын дип» күзәтеп торачакларын әйтәләр. Элек тыныч вакытта да андый өйрәнүләр була иде ул. Ләкин хәзер вазгыять катлаулы булгач, сискәндерә. Американнар үзләре дә нәкъ менә бу көннәрдә Европада нәкъ шундый өйрәнүләр үткәреп яталар. Алар, Россия атом коралы белән һөҗүм итсә, җавап бирү ысулларын кабатлыйбыз, диләр. Ике як та бер-берсен куркытмакчы була, ике як та мускуллар уйната. Атаклы Америка инвесторы Илон Маскның нервлары чыдамады, соңгы көннәрдә ул, яулап алган җирләрне Путинга калдырып, тизрәк конфликтны туктатырга чакырды. Украиннар аны шуның өчен сүгәләр, Путинга сатылган дип әйтәселәре килә. Бик зур байлыклар иясе булarak, Маскның хәлен аңларга мөмкин: кемнең рәхәт тормыштан бер шартлау аркасында аерыласы килсен.

«Гром» дип аталган өйрәнүләр октябрь ахырында башланыр һәм берничә көн дәвам итәр, диләр. Россия хәрбиләре Баренц диңгезенең кимендә җиде районын япканнар, башка төбәкләрдә дә шундый чикләүләр бар. Көнбатышлылар, атом-төш коралларын сынау шул төбәкләрдә үткәрелер, диләр.

Хәрби конфликт зонасында хәл киеренке. Әмма финанслар өлкәсендә дә шулай ук ул. Америка санкцияләре акрынлап Россия бизнесы өчен боҗраны кысалар. «Мир» картасын кулланырга мөмкин булган илләр калмады диярлек. Гонконгта чыгучы South China Morning Post басмасы: «Санкцияләр аркасында россиялеләрнең Гонконг банклары белән проблемалары башланды», – дип хәбәр итә. Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә дә вазгыять шуңа таба үзгәрә. Россия бизнесының анда да банклар белән эш иткәндә кыенлыклар кичерүе мәгълүм булды. Хәзер анда хисап ачу бик авыр, компания ачу сроклары да озынайтылды.

Россиянең эчке мәйданында исә чиновникларны авызлыкларга, ришвәт белән табылган малдан файдалануны катлауландырырга ниятлиләр. Хөкүмәт Дәүләт Думасына түрәләрне, зур кредитлар алганда, бу хакта отчет бирергә мәҗбүр итә торган канун проекты кертте. Кредитны нинди чыганактан каплыйсы икәнен дә әйтергә кирәк булачак.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ЯЛЫ ДА ҮЗЕБЕЗДӘ

Якын киләчәктә Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында табигатьтә ял урыннары (глэмпинг. – Ред.) пәйда булачак. Кичә Хөкүмәт йортында Рөстәм Миңнеханов катнашында узган Татарстан инвестицион советы утырышында аларның проектлары тәкъдим ителде. Моннан тыш утырышта тагын биш инвестицион проект каралды. Алар да, нигездә, туризм тармагына карый.

Рөстәм Миңнеханов, утырышны башлап, яңа вазгыятьтә республиканың бу юнәлештә дә сынатмавын искәртте. «Татарстан килеп туган геосәяси вазгыятьтә дә инвестицияләр җәлеп итә, яңа инвестицион проектлар тормышка ашыра белә», – диде Президент.

Утырышта тәкъдим ителгән беренче инвестицион проект Югары Ослан районында табигатьтә ял урыны төзүне күздә тота. «For-Rest Glamp» проекты җитәкчесе Илья Спиридонов сүзләренә караганда, глэмпингта ял йортлары, мунча, ашау-эчү, барбекю зонасы урнашыр дип көтелә. Ел әйләнәсе эшләячәк әлеге ял урынында 36 эш урыны да булдырылачак, дип ышандыралар.

Шундый ук глэмпинг Кама Тамагында да пәйда булачак. Аның беренчесе Юрьев мәгарәсе янында урнашыр дип көтелә. Аның проектын «Середина Волги» оешмасы белгечләре эшләгән. Биредә ял йортлары, палаткалы лагерь, фестиваль зонасы белән остаханәләр эшләр дип көтелә. Кама Тамагындагы икенче глэмпингны исә Лобач тавыннан ерак булмаган җиргә урнаштырырга тәкъдим итәләр.

Утырышта тәкъдим ителгән тагын бер инвестицион проект Яшел Үзән районында шәһәр яны комплексы төзүне күздә тота. 150 номерлы кунакханә, 37 вилла, спа-комплекс, медицина бүлмәсе, мунча, спорт мәйданчыклары урнашкан әлеге урында ял итеп кенә түгел, сәламәтлекне дә ныгытып булачак, дип ышандыра проект авторлары. Мотоспортны үз итүчеләр өчен исә Яшел Үзән районында махсус спорт-туризм базасы төзергә тәкъдим итәләр. Проектны эшләгән «Фаворит Плюс» оешмасы башлыгы Айдар Галиев сүзләренә караганда, биредә 120 кешегә исәпләнгән кунакханә дә урнашачак.

Инвестицион утырышта тәкъдим ителгән тагын ике проект исә ягулык салу станцияләре инфраструктурасын үстерүне күздә тота. Утырышта тәкъдим ителгән барлык проектлар да хупланды.

– Инвесторларыбызга рәхмәт. Бу – бик мөһим проектлар. Районнарыбызда кемпинг, кирәкле инфраструктурасы булган ял зоналары үсү бик яхшы. Бу тармакта алга таба да эш алып барырга кирәк. Табигатебез бай, матур урыннарыбыз күп. Кешеләргә чит төбәк һәм илләргә китмичә, үзебездә генә ял итәрлек шартлар тудырырга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

ӨМЕТЛЕ ЯШЬЛӘР

tatarstan.ru

Сез яулаган һәр медаль – Татарстан өчен зур уңыш. Президент Рөстәм Миңнеханов илкүләм «Яшь профессионаллар – 2022» чемпионаты җиңүчеләрен әнә шундый сүзләр белән тәбрикләде.

Быел да сынатмадылар. Татарстан җыелма командасы илкүләм «Яшь профессионаллар – 2022» һәм Евразия чемпионаты нәтиҗәләре буенча Россия төбәкләре арасында лаеклы икенче урынны яулады. Рөстәм Миңнеханов республиканың яшь осталары белән очрашуда билгеләп үткәнчә, Татарстан кабаттан һөнәри осталык буенча алдынгы урында булуын раслады. Очрашуда WorldSkills Russia оешмасының генераль директоры Роберт Уразов, Татарстанның Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе Шамил Гафаров та катнашты.

Шуны әйтергә кирәк: илкүләм чемпионатның финалы белән бер үк вакытта Евразия чемпионаты да узды. Монда да безнең яшьләр сынатмады – республика исеменнән катнашкан һәр конкурсант беренче урынны яулады.

– Сез яулаган һәр медаль – Татарстан өчен зур уңыш. Мондый нәтиҗәләргә ирешү өчен, эшне билгеле бер системага салырга, бер минут та туктап тормыйча әзерләнергә, һөнәри осталык күнекмәләрен ныгытырга кирәк. Шуннан башка уңышка ирешеп булмый. Бүгенге чемпионнарны һәм призлы урын яулаган яшьләрне югары нәтиҗәләргә ирешүләре белән котлыйм! Аларга һәрьяклап ярдәм күрсәткән, белем биргән экспертларга, тренерларга, укытучыларга, шулай ук чемпионат хәрәкатендә югары нәтиҗәләргә ирешкән уку йортлары җитәкчеләренә аерым рәхмәт! – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент әлеге ярышларның Татарстандагы һөнәри белем бирү өлкәсе өчен зур әһәмияткә ия булуын да ассызыклады.

– Инде менә 10 ел дәвамында чемпионат кадрлар әзерләүдә уңышлы яңа технологияләр кертүнең нәтиҗәле чарасы булып тора. Һөнәри осталык чемпионатында җиңү яулыйсыз икән, булачак эш бирүчегез алдында бу өстәмә плюс булачак. Югары нәтиҗәләргә ирешсәгез, бәхәссез өстенлеккә ия булачаксыз, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Республика алга таба да «Яшь профессионаллар» чемпионаты хәрәкәтенә ярдәм итәчәк. Аның югары стандартларын мәгариф өлкәсендә кулланырга кирәк. Һәм кулланачакбыз да. Бүген махсус хәрби операция уздыру шартларында һәркем үз эшенә һәм сайлаган һөнәренә җаваплы карарга тиеш. Бу яхшы нәтиҗәләргә ирешергә, димәк, Россиягә җиңү яуларга ярдәм итәчәк. Бары тик бергә булганда гына без илебезнең яңа бурычларын хәл итә алачакбыз.

Очрашу кысасында катнашучыларга дәүләт бүләкләре – Татарстан Президенты һәм Татарстанның Министрлар Кабинетының Рәхмәт хатлары тапшырылды.

Эш батырыннан – ил батырына

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«КАМАЗ» мобилизацияләнгән хезмәткәрләренә ай саен 50 мең сум акча түләячәк. Хәзерге вакытта 21–35 яшьләрдәге 35 хезмәткәр чакырылды, дип хәбәр итә «КАМАЗ»ның матбугат үзәге. Шулай ук, мобилизацияләнгән профсоюз әгъзаларына бер тапкыр 25 мең сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтеләчәк. «Безнең егетләрне бигрәк тә туганнарына ярдәм күрсәтеләчәге шатландырды. Аларны һәрдаим кайгыртачакбыз», – диде компаниянең генераль директоры киңәшчесе Александр Евграфов.

«Татнефть» һәм «Казэнерго»ның мобилизацияләнгән хезмәткәрләре 50 мең сумлык түләүләр алачак. «Казэнерго»ның 30дан артык хезмәткәре чакырылган. Алар белән хезмәт килешүләре туктатылган, өстәмә килешүләр төзелгән. «Татнефть»тә мобилизация буенча сорауларга җавап бирү өчен махсус штаб булдырылган. Чакырылган хезмәткәрләрнең гаиләләренә волонтерлар ярдәм итәчәк. Энергетика, газ эшкәртү производствосы кебек стратегик мөһим инфраструктура объектларында эшләүче хезмәткәрләргә бронь бирелә.

Сан

Республикада нинди белгечлекләргә ихтыяҗ зур?
Җитештерү өлкәсе – **42,1**% (**31,2** мең эш урыны бар);
Төзелеш һәм күчемсез милек өлкәсе – **9,3**% (**6,9** мең);
Мәгариф һәм фән – **4,4**% (**3,3** мең);
Транспорт – **6,1**% (**4,5** мең);
Сәламәтлек саклау – **4,4**% (**3,3** мең);
Азык-төлек сәнәгате – **4,1**% (**3** мең);
Сату һәм көнкүреш хезмәт күрсәтү – **4,6**% (3,4 мең);
Консалтинг – **3,5**% (**2,6** мең);
Башка өлкәләр – **21,5**% (**15,9** мең).

Ләйсән САФИНА

Ялгыз калмаячаклар

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Авырлы хатыннар бәби табуга ук бөтен кирәк-яраклар тутырылган тартма алачак, – ди Эльмира Зарипова. – Ирләре генә эшләп, үзләре өйдә утырган ханымнар өчен дә яңадан укыту оештырыла. Аларны иң элек 3 көн эчендә эшсез дип билгелибез һәм пособие алу мөмкинлеге бирәбез. Аннары инде нинди юнәлештә эш урыннары бар, шул һөнәргә кабат укытабыз. Болар бушка эшләнә. Әгәр хатын-кыз кул эше белсә, үзенең ниндидер һөнәре бар икән, аларга үзмәшгуль булып теркәлергә киңәш итәбез. Дәүләт эш башлаганда кире кайтарып бирмәү шарты белән 145 мең сум акча бирә.

Эш дигәннән, өлешчә мобилизацияләнүчеләрнең элек хезмәт куйган урыннары да сакланачак. Махсус хәрби операциядә чакта аларның эш стажлары саклана.

Очрашуда өлешчә мобилизацияләнүчеләрнең сәламәтлеге хакында да сөйләштеләр. Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская сүзләренчә, алар оештырган «кайнар линия»гә бик күп төрле сораулар килә икән.

– Татарстанда өлешчә мобилизацияләнгән солдатларның 800е медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итте. Закон буенча кабат медицина тикшеренүе үткәрелми. Әмма без, күп үтенечләрне исәпкә алып, уздыра башладык, – ди ул. – Армиядән кайта да кеше тыныч кына яши башлый. Авырса да, бу хакта әйтми, тикшеренми. Ә бит сәламәтлек белән проблемалар бар икән, табибка күренергә, бу хакта хәрби эшегезгә беркетүләрен сорарга кирәк иде. Сәламәтлеккә карап хезмәткә яраклылык үзгәрә бит. Хәзер дә өлешчә мобилизацияләнүчеләр җыелган урыннарда табиблар эшли. Сәламәтлеге начарланган кешеләр алар янына барырга, кирәк икән, тикшеренү өчен хастаханәләргә чыгаруны сорарга тиеш. Авырулар турында алдан белдертергә кирәк булган да бит. Тик беребез дә мондый хәлләр булыр дип көтмәдек шул. Әле хәзер дә салкын тигән яки башка хроник чирләр кузгалган икән, хәбәр итәргә кирәк.

Очрашуда өлешчә мобилизацияләнүчеләр өчен бирелә торган кредит каникуллары турында да сөйләштеләр. Баксаң, барлык банклар да түләүләрне кичектереп тормый икән. Кредит каникулы биргәннәрнең дә кайберләре 9 ай өчен 75 мең сум өстәмә түләргә кирәклеген җиткергән. Әлегә бу юнәлештә тә ачыклыйсы эшләр бар. Шулай ук уллары мобилизацияләнгән, ярдәмгә мохтаҗ өлкән яшьтәге кешеләр дә бар. Андыйларга волонтерлар ярдәм итә. Бакчадагы эшләрендә дә булышалар, кирәк-яракларын да алып кайтып бирәләр.

Ә өлешчә мобилизацияләнүчеләргә бездән ни кирәк соң? «Ярдәм янәшә!» иҗтимагый хәрәкәте координаторы Тимур Сафин җылы киемнәрнең артыгы булмас, ди. «Оекбашлар, җылы эчке киемнәр, алмаш курткалар беркайчан комачау итмәячәк. Аларга хәзер кием генә түгел, җылы сүзебез дә көч өсти», – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАДЕРЕН БЕЛМИБЕЗ

Экология

Сулыклар пычрана. Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы әнә шулай дип чаң суга. Суга чүп тә ташлыйлар, пычрак та агызалар. Беренчесе кешеләр кулы белән эшләнсә, икенчесен оешмалар башкара. Министрлыкка су төсенең үзгәрүеннән зарланып мөрәҗәгать итүчеләр күп икән.

Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Идел-Кама территориаль идарәсе инспекторлары Аксубай районының Кече Сөлчә елгасына пычрак су агызучыларны ачыклаган. Елгага агучы сулар аксыл төстә булган. Министрлык лабораториясе хезмәткәрләре су агызу урынында да, шулай ук елганың югары һәм түбән өлешләреннән дә су пробаларын алган. Суда аммоний, фосфат ионнары һәм нефть продуктларының күп күләмдә булуы ачыкланган. Әлеге эш табигатьне саклау районара прокуратурасына тапшырылган.

Әлмәттә яшәүчеләр дә «Күлләр каскады» паркы янындагы су сыйфатыннан зарланган. Биредә дә су пробалары алынган. Моңа кадәр су төсеннән зарланучы булмаган. Хәлне ачыклау өчен, экологлар бу паркка барган. Тикшерә торгач, биредә яңгыр сулары агызыла торган канализация челтәрләренә эксплуатация оешмасын билгеләргә кирәклеге ачыкланган. Баксаң, биредәге «яңгыр канализациясе» хуҗасыз икән. Янәшә йортларда яшәүчеләр исә бу урынга сәнәгать оешмасы һәм машина юу станциясеннән пычрак сулар ага дигән фикердә. Әлегә тикшерү эшләре бара.

Түбән Кама халкы да актив. Алар экологларга Омшанка елгасына агып ятучы күбекне күрүләре турында хәбәр иткән. Экология министрлыгының Кама аръягы территориаль идарәсенең экологик күзәтчелекне тәэмин итү бүлеге белгече Татьяна Мухина сүзләренчә, Омшанка елгасыннан су пробалары алынган. Хәзер алар тикшерелә. Әлеге пычрак су якын-тирәдәге берәр машина юу станциясеннән агып ятарга мөмкин, диләр.

Күптән түгел экологларга Казансу елгасына да пычрак су агып ята дигән хәбәр килеп ирешә. Инспекторлар Арча районына юл тота. Баксаң, андагы сулык өсте аксыл төскә кергән була. Инспекторлар ул урынны тикшерә башлый.

– Арча районында яшәүчеләрдән шикаятьләр еш килә. Җәй көне алар аеруча күп иде, – ди Татарстанның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Елена Веселова. – Җәй көне су өсте сөт төсенә кергән иде. Ул чакта безнең инспекторлар Чуриле авылына юл тотты. Гаеплеләрне дә ачыкладылар. «Водоканал-Сервис» һәм Арча сөт комбинатыннан Казансуга пычрак сулар агып яткан иде. Лаборатор нәтиҗәләр суның бик начар сыйфатлы икәнен күрсәтте.

tatarstan.ru

Без инде Арча сөт комбинаты турында берничә кат язган да идек. Ул чакта алар Шушма елгасын пычратып телгә керделәр. Аларга 80 мең сум штраф салырга һәм табигатькә китерелгән 6 миллион сумлык зыянны капларга дигән карар чыгарганнар иде.

Хәер, штраф белән куркытып булса иде ул. Аннан гына курыкмыйлар. Эчәр су, сулар һава чиста булсын дисәк, һәркемгә табигатькә сакчыл карарга кирәк. Сусыз яшәп булмаганын белсәк тә, без әле дә аның кадерен белмибез.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЮГАЛМАСКА НӘСЕЛ КИРӘК

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Җирдә эзсез югалмас өчен, нәсел-нәсәпне барларга, шәҗәрәләр төзергә кирәк, дигән фикердә «Без тарихта эзлебез» бәйгесендә Кайбыч районын яклаган Баһавиевлар гаиләсе. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты оештырган бу бәйге турында ишеткәч, алар үзләрен сынап карарга булалар.

– Дөрес, әзерләнергә бик аз вакыт калган иде инде, – ди Энҗе ханым. – Шулай да тәвәккәлләдек, сынатмадык, икенче урынга лаек булдык. Яшел Үзән шәһәрендә узган зона ярышына 16 кеше җыелып бардык. Шулар арасында иң олысы 82 яшьлек әбиебез – әнием Розалиянең әнисе Рәшидә иде. Ул да бик теләп барды. Ярышта катнашучы гаиләләр арасында үзебез иң яше булдык. Гаилә корганыбызга 8 ел гына әле. Ике кыз үстерәбез. Ләбибә кызыбыз Кошман мәктәбенең 1 нче сыйныфында укый. Назилә шул ук авылның «Тиенкәй» балалар бакчасына йөри. Нәсел агачын барлау безнең өчен зур яңалык та булмады үзе. Мин әбиле-бабайлы гаиләдә үстем. Бәләкәй чакларда әбием янына тирә-юньдәге күршеләр кереп, үзләренчә үткәннәрне искә төшереп утыралар иде. Гел алар янында булгач, бик күп әйбер башыма сеңеп калган, күрәсең. Хәтерлим әле, башлангыч сыйныфларда укыганда, нәсел агачын төзеп килергә куштылар. Әни, әти, әби – барыбыз бергә туганнарыбызны барлап утырдык. Ирем Ленар ягында да кызыксынучылар булган. Кайчандыр апасы Гөлнара нәсел агачын төзегән. Хәзер инде кәгазьдә генә ясалган шул шәҗәрәне зурайтып куярга йөрибез.

Үзләре район үзәгендә яшәсәләр дә, Кошманны үз итүләренең сәбәбе бар Баһавиевларның. Энҗе шул авылда туып-үскән. Югары уку йортын тәмамлагач та, озак уйланып тормаган: туган авылына кайткан да рус теле һәм әдәбияты укытырга керешкән. Аннан башлангыч сыйныф укучыларына белем бирә башлаган. Җырлы-моңлы гаилә булулары да гаҗәп түгел. Ире Ленар Кайбыч мәдәният йортында эшли, халык театрында спектакльләрдә катнаша.

– Бәйгедә әти-әниләребез, туганнарыбыз бик зур терәк булдылар, – ди Энҗе. – Башта үзебез әзерләп килгән камыр ризыкларыннан чәй табыны әзерләдек. Пәрәмәч, бәлеш, өлеш, кыстыбый, бавырсак, кош теле, гөбәдия, өчпочмак, чәкчәк, коймак – барысы да бар иде. Үзенчәлек буларак, Кошман авылына гына хас булган мичтә юка пешерү йоласын тәкъдим иттек. Кызларыбыз шул тәм-томнар турында бик матур шигырьләр сөйләделәр.

Гаилә, нәсел җепләре белән таныштырганда, алар буыннан-буынга мирас булып калган, хәзер инде сандыкта урын алган байлыкка мөрәҗәгать иткәннәр. Анысы әбисеннән – әтисенең әнисе Саймәдән калган хәзинә икән. Анда чиккән сөлгеләр, көмеш беләзекләр, йөзекләр, бизәнү әйберләре, күлмәкләр саклана, хәтта әнисе Розалиянең туй күлмәге дә шунда урын алган. Бөтенләйгә «эшсез» ятмыйлар икән үзе. Әбиләре Сайманең әнисеннән калган көмеш йөзекләре Энҗегә күчкән. Бабасы Зөфәрнең әнисе Рәйсәгә 1815 елда әтисе бүләк иткән «Зингер» машинасы бөтен авылны киемле иткәнен дә ачыклаган алар. Рәйсәгә ул вакытта 15 яшь булган.

– Кеше гомере бик кыска, – ди Энҗе ханым. – Күп туганнарыбыз безнең күңелләрдә инде якты бер истәлек булып кына яши. Нәселебездә атаклы кешеләр булмаса да, төрле һөнәр ияләре бар. Чишмә башыбыз ике яктан да җир кешеләренә барып тоташа. Без ачыклаган кадәре алтынчы буын Бикчәнтәй бабабыз да, бишенче буын Миңнулла, дүртенче буын Нәбиулла бабаларыбыз да җир кешеләре булып гомер кичергәннәр. Ирем ягыннан Баһави, Әбзәл, Низами, Фирдәвес бабаларыбыз, минем яктан Садри, Гыйлаҗ, Әбрар, Рөстәм бабаларыбыз – барысы да игелекле, хезмәт яратучы кешеләр булганнар. Телебезне, динебезне, милли йолаларыбызны хөрмәт иткәннәр. Без алар белән горурланабыз. Өченче буын бабаларыбызга Бөек Ватан сугышында катнашырга туры килгән. Әбрар белән Әбзәл бабам яудан исән-сау кайта алганнар, ә менә Габбас, Һади, Борһан бабаларым сугыш кырында ятып калган.

Буыннан-буынга килгән һөнәрләрне дә дәвам иттерүчеләр бар бу нәселдә. Балчыктан кирпеч ясаучылар да булган. Хәзер бу эшне Энҗенең әтисе Рөстәм дәвам иттерә икән. «Авылыбызда, районыбызда гына түгел, тирә-яктагы җирлекләрдә дә йорт салуга күп өлешен кертә әтиебез», – ди ул. Ул үзе дә әби-бабалары, әти-әниләренең эшен дәвам иттерә.

– Нәселебездә ике буынга 185 ел хезмәт куючы укытучылар бар, – ди бу җәһәттән. – Санап та чыктык: барысы сигез укытучы. Үзем дә, әнием Розалиядән үрнәк алып, шушы һөнәрне сайладым. Хәзер дә аның тәҗрибәсенә таянам. Бәйгегә әзерләнгәндә дә нык ярдәм итте. Нәселебездә ике яклап биш шәфкать туташы, хезмәт юлларын бергә кушып санасаң – 155 ел. Арабызда китапханәче һөнәрен үз итүчеләр дә, һәвәскәр шагыйрьләр дә бар. Умартачылык һөнәре дә буыннан-буынга килә. Хәзер бу эшне ирем ягыннан әтиебез Фирдәвес дәвам иттерә.

Укытучылар турында сүз чыккач, шунысын да әйтик: Энҗе ханым «Ватаным Татарстан» журналисты Чулпан Гарифуллинага да белем биргән, сыйныф җитәкчесе булган. Хезмәттәшебезнең бик актив, белемле, идеяләргә бай булуында, тарих белән кызыксынуында, һичшиксез, укытучы апасының да өлеше зурдыр, дип уйларга кирәк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Кичәге көн тарихта кала

Архив эше

Казанда илебездәге дәүләт архивлары фондларын саклаучылар тәҗрибә уртаклаша.

Россия күләмендә уздырылган бу киңәшмәнең нәкъ менә башкалабызда билгеләнүе очраклы түгел. Архив өлкәсендә башкарылган эшләргә килгәндә, Татарстанның мактанырлыгы да, сөйләр сүзе дә, тәҗрибәсе дә бар.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразыев бу җәһәттән чагыштырулар да китерде.

– Әле кайчан гына пенсия рәсмиләштерү яисә чит ил паспорты алу өчен генә дә без, арлы-бирле чабып, белешмәләр җыярга мәҗбүр идек. Хәзер исә архив документлары цифрлаштырылган. Дәүләт хезмәтләре порталына керәсе дә, кирәк әйбереңне табып, гариза гына язасы. Искиткеч җайлы бит. Архив дигәч тә, безгә ул бик ерак үткәннәр булып тоела. Әмма ул алай түгел. Кичәге көн инде фотографияләр, текстлар белән тарихка кереп кала. Бу һәрберебез өчен бик мөһим. Бүгенге киңәшмәдә катнашучыларны, мөгаен, төрле сораулар кызыксындыра торгандыр. Шуңа да иң кирәклесе – аралашу, дип уйлыйм.

Россия Архив федераль агентлыгы җитәкчесе урынбасары Андрей Юрасов исә бу фикерләрне җөпләде.

– Татарстан архив эшләрен җайлау, документларны саклау буенча Россиядә башкаларга үрнәк булып тора. Соңгы елларда монда, чыннан да, бик күп эшләр башкарылды. Моның шулай икәнлегенә башкаларны да инандыру өчен, делегация беренче чиратта 8 Март, Декабристлар урамнарында һәм Лаеш районының Столбище авылында урнашкан архив биналарына сәяхәт кылды. Алардагы куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү, янгыннан саклау системалары, чыннан да, сокланырлык һәм үрнәк алырлык, – диде ул.

Киңәшмәдә аз да түгел, күп тә түгел, җәмгысы ун тема күтәрелә. Алар берсен берсе тулыландыра. Беренче чиратта, әлбәттә инде, модернизацияләүгә, заманча технологияләргә кагылышлылары тора. Документларның иминлеген тәэмин итү – бүген иң мөһиме, дип саный архивчылар. Теге яки бу документларның бармы яки юкмы икәнлеген ачыклау да зур роль уйный. Кайбер төбәкләрдә әле күп кенә документлар канәгатьләнерлек хәлдә түгеллеген әйттеләр. Аларны да тәртипкә китерәсе бар. Фондта саклаучы аеруча кыйммәткә ия, уникаль документларны иминиятләштерергә, тиз арада цифрлаштырырга да кирәк. Документларны исәпкә алучылар әйтүенчә, андыйлар, чыннан да, күп икән.

Быел Бөтенроссия дәүләт архивларын саклаучы фондларның киңәшмәсе үзенә күрә юбилеен да үткәрә. Моннан 20 ел элек, 2002 елның ноябрь аенда Түбән Новгород шәһәрендә мондый форматтагы киңәшмәнең беренчесе үткәрелгән. Аннан, традициясе дәвам итеп, Санкт-Петербургта, Самарада, Пензада, Нальчикта оештырыла. Әмма бу киңәшмәләр аерым бер темаларга гына багышлана. Ә барлык юнәлешләрне үз эченә алганы икенче тапкыр гына оештырылган икән. Казанда үткәрелгәне шуңа күрә дә икенче киңәшмә дип исәпләнә. Бүген монда Россиянең 69 төбәгеннән 245 белгеч килгән, 26 төбәктән онлайн формада катнашалар.

Васил Шәйхразыев, шаярту катыш, чараларның күңел өчен оештырылганнары да бар, көннәр дә матур тора әле, дип әйткәч, залда җиңелчә генә гөжләү пәйда булган иде. Сәбәбе дә бар: көннәр яңгырлы бит. Ә кунакларның күрәсе, йөрисе урыннары бик күп. Эш беткәч, уйнарга ярый, дигәндәй, өч көн фикер алышкач, алар «Россия – минем тарихым» дип аталган тарихи паркны, «Идел буе Болгарстанында ислам динен кабул итүгә 1100 ел» күргәзмәсен карарга җыеналар. Аннан Изге Болгарга бару тәгаенләнгән.

Гомерен, эшчәнлеген архив документларын саклауга багышлаган кешеләр өчен эш буенча тәҗрибә уртаклашу гына түгел, мондый тарихи объектларны күрү дә, һичшиксез, файдалы да, кызыклы да булачак.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ВАТАННЫ ЯРАТУ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сораштыру

Яшьләр дөньяны башкача кабул итә. «Алар патриотизм, игелекне дә башкача аңлый, өстәвенә туган телләре, милләте белән кызыксынмый», – дигән сүзләрне еш ишетергә була. «Y» һәм «Z» буыны вәкилләре чыннан да үзгәме? Шуны ачыклау өчен, яшьләрдән Ватан төшенчәсе һәм милләтне саклап калу хакында сораштырдык.

Илсаф САФИН, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәре:

– Ватанны мин әниемә тиңлим, чөнки Ватан ул – кеше күңеленә Ана сөте белән салынган туган җир. Шуңа да ил өчен мин барысына да әзер: хәзер, мәсәлән, Казанда ГТХМда эшлим. Бу һөнәрне, әлбәттә, бәлагә очраган кешеләргә ярдәм итү өчен сайладым.

Милләтемне саклар өчен, мин татар телендә сөйләшергә тырышам. Күпме телне өйрәнсәң дә, ана биргән туган телеңне саклап калу – безнең бурыч, тик аның өчен беренче чиратта гаилә җаваплы. Гомумән, яхшылыклар гына кылып, туган илеңне, телеңне онытмаска, милли йолаларны һәм гореф-гадәтләрне киләсе буынга тапшырып, әти-әниеңә булышып яшәргә кирәк.

Илнар ИДРИСОВ, блогер:

– Ватан дигәндә, мин туган ягымны, әти-әниемне, дәү әниемне, туганнарымны һәм дусларымны күз алдыма китерәм. Ә инде татар халкын һәм телен популярлаштырыр өчен, мин милли киемнәр киеп, татар халык җырларына яздырылган каверлар кулланып, видео төшерәм дә аны социаль челтәрләргә куям. Нәтиҗәдә шушы вайннарны, гомумән, вируслы видеоларны төрле яклардагы татарлар карап, бергә җыелалар сыман.

Ләйсән ӘХМӘТҖАНОВА, КНИТУ-КАИның 3 нче курс студенты:

– Һәр кеше Ватан төшенчәсен үзенчә аңлый. Кемгәдер ул туган авылы, йорты, ә башкаларга – туган иле, республикасы. Минем өчен ул – әлбәттә, Татарстан.

Берничә ел элек мин ракета двигательләрен төзү буенча инженер һөнәрен сайлап, КНИТУ-КАИга укырга кердем. Киләчәктә туган илемне шуның буенча яңа баскычка күтәрергә телим. Тик әлегә мин югары уку йортымда студентлар өчен төрле чаралар оештырам. Һәм үзара сөйләшүләр нәтиҗәсендә шундый фикергә килдем: яшьләрне патриотик рухта әхлакый тәрбияләү гаиләдән башлана. Иң мөһиме – әти-әниеңне, әби-бабаеңны, туганнарыңны хөрмәт итү, аларның хәлләрен белү, аларга булышу.

Фазыл ГАФИЯТУЛЛИН, И.И. Мечников исемендәге Санкт-Петербург дәүләт медицина академиясе дәвалау факультетының 6 нчы курс студенты:

– Түбән Кама шәһәреннән 1,5 мең километрга якын ераклыкта булсам да, туган ягымны еш искә алам. Дуслар белән йөри торган юллар, әти-әнием янында бер кайгысыз үскән йортым – боларның барысын да онытырга мөмкин түгел. Ә инде бүген мин медицина академиясендә соңгы 6 нчы курста укып, якын-тирәдәге хастаханәдә шәфкать туташы булып эшлим. Кешегә файда китерер өчен, нәкъ шушы табиб һөнәрен сайладым дисәм, ялгышмамын.

Бездә «Ни чәчсәң, шуны урырсың» дигән мәкаль бар. Бу – яшьләр ата-аналарыннан үрнәк ала дигән сүз. Димәк, башта үз-үзеңне тәрбияләргә кирәк. Шуңа мин Санкт-Петербург шәһәрендә яшәсәм дә, әти-әнием, апа-абыйларым, дусларым белән бары тик туган телемдә сөйләшергә тырышам. Монда татар телен белүчеләр бик аз, кызганыч, ә милләтне сакларга кирәк!

Диана АХУНОВА, яшьләр белән эшләүче белгеч:

– Ватан ул – туган җирем, көч алу урыным. Мин үземне чын патриот дип саныйм, чөнки бөтен танышларга, дусларга гел Татарстанның даны турында сөйлим. Кайда гына булсам да, нинди матурлыкны күрсәм дә, Татарстан – иң яхшы урын, дип әйтәчәкмен, димәк, үз-үземә һәм, әлбәттә, Ватаныма хыянәт итмәячәкмен.

Яшьләр белән эшләүче белгеч буларак, милләтне, туган телне саклау өчен, төрле чаралар, акцияләр, популяр русча уеннарны татар телендә оештырам. Әйтик, «Татар-дозор» квест-уены йә «Татарча Мафия». Ә инде яшьләрдә ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләү турында әйтеп китсәк, хөкүмәт яхшы яшәү шартлары тудырса һәм кешегә туган илендә яшәргә рәхәт булса, ул үзеннән-үзе патриот булачак.

Рәдис ГАРИПОВ, Туфан Миңнуллин исемендәге Татар дәүләт драма театрының артисты, блогер:

– Ватан турында уйлагач, мин туып-үскән ягымны – Актаныш районының Усы авылын күз алдыма китерәм. Анда мине көтеп тора торган әти-әнием, әби-бабайларым яши. Гомумән ул – бөтен туганнарны берләштерә торган очрашу урыны, димәк, шушы нигезне гел ныгытырга кирәк.

Татарстанда яшәгәч, көн саен туган телемдә сөйләшергә тырышам: татар театрында уйныйм; вайннар, пранклар һәм авыл тормышын төшереп, социаль челтәрләрдә блогымны татарча алып барам. Болар барысы да туган телне саклауга барыбер ниндидер өлеш кертә, дип уйлыйм.

Әлбәттә, яшьләрне өйрәтергә, үзгәртергә кыен: аларның үз кызыксынулары, тормышка үз карашлары, үз фикерләре бар. Тик аларга дөрес тәрбия генә бирергә кирәк. Гомумән, һәр кеше үз баласын тәрбияләсә, шул җитә. Иң беренче чиратта, татарлыгыңнан оялмаска! Дусларың, туганнарың, аралаша торган кешеләрең белән татар телендә сөйләшергә кирәк.

Диана КАРПОВА,
КФУның 2 нче курс студенты

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Гигант» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Имамов** Риф Хәниф улы, «Игенче» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы тракторчысы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Мөхәммәтшин** Габделхәй Әхмәтша улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Калморза» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте идарәсе рәисе (Татарстан Республикасының Минзәлә районы) **Шәрипов** Алмаз Хантимер улы **Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Апас-Мол» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең агрономия хезмәте агрохимигы (Татарстан Республикасының Апас районы) **Габбазов** Роберт Ринат улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең әйдәүче агрономы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Быков** Юрий Ефремовичка, Никита Евдокимович Токарликов исемендәге акционерлык җәмгыятенең орлыкчылык буенча агрономы (Татарстан Республикасының Әлмәт районы) **Җамалиев** Ирек Мингаяз улына, «Ямбулат» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы баш агрономы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Зәйнетдинов** Рәфис Миңназыйм улына, «ОРСИС-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы хезмәтенең «Сухарево» бүлекчәсе агрономы (Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) **Каюмов** Нәфис Вахит улына, «Аксу Агро» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте агрономы (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Минапов** Хәлил Хәлим улына, «Чистай» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш агрономы(Татарстан Республикасының Чистай районы) **Родионов** Александр Ивановичка, «Азык-төлек программасы агросәнәгать компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте үсемлекчелек буенча дирекциясенең «Тәкәнеш» бүлекчәсе өлкән агрономы (Татарстан Республикасының Мамадыш районы) **Степанов** Иван Тимофеевичка **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Нурлат-Сөте» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Нурлат районы) **Гаврилова** Алевтина Николаевнага, «Кама Беконы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 5300 комплексы 1 номерлы цехының 1 номерлы участогында терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча операторы (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Кайнова** Наталья Михайловнага, «Азык-төлек программасы агросәнәгать компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Малмыж» терлекчелек комплексының машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Мамадыш районы) **Мирхазова** Чулпан Кыям кызына, «Кызыл Шәрык Агро» акционерлык җәмгыяте «Вахитов» терлекчелек комплексының машина белән сыер саву өлкән операторы (Татарстан Республикасының Зеленодольск районы) **Нигъмәтуллина** Гөлинә Габбас кызына, «Кармалы» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчесе (Түбән Кама шәһәре) **Решетников** Виктор Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«АксуАгро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Җамалетдинов** Илнар Әсхәт улына, «Татспиртпром» акционерлык җәмгыятенең «Мамадыш спирт заводы» филиалы тракторчысы (Мамадыш шәһәре) **Козлов** Николай Степановичка, «Август-Теләче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы машиналарын һәм җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча слесаре (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Мөхәмәтҗанов** Яхия Мансур улына, «Зәй шикәре» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Зәй районы) **Никандров** Михаил Васильевичка, «Зәй шикәре» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Зәй районы) **Никодимов** Марс Фоат улына, Никита Евдокимович Токарликов исемендәге акционерлык җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Әлмәт районы) **Плягин** Радик Алексеевичка, «Калморза» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Минзәлә районы) **Якупов** Фәндүс Ильяс улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«БАЛТАЧАГРОХИМСЕРВИС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Чепья механика отряды башлыгы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Дәминов** Марат Мансур улына, «Уңыш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Зәйнуллина** Рәмлә Рәфкать кызына, «АгроРаздолье» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Яңа Чишмә районы) **Козлов** Алексей Анатольевичка, «Миңнеханов Рәмис Минталип улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Миңнеханов** Рәмис Минталип улына, «Мифтахов Данис Бәдртдин улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Апас районы) **Мифтахов** Данис Бәдртдин улына, «Таллы-Бүләк» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Мотыйгуллин** Наил Фоат улына, «САРМАН» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры (Татарстан Республикасының Сарман районы) **Нургалиев** Илшат Әзһәр улына, «КУКМАРА СӨТЕ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Хәмәтдинов** Миңнефәнис Фәлахетдин улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Тукай районының Иске Дөреш авылында яшәүче кадерле апабыз ХАРИСОВА Тәзкирә Гыйльметдин кызы 20 октябрьдә 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Апабыз ире Гатуф абый белән бик матур гомер кичерде. Хәзер улы Илшат, килене Дания тәрбиясендә яши. Гомер буе балаларга татар теленнән белем бирде. Ул Зөһрә Сәхәбиеваны да укыткан.

Тәзкирә апа, сезне юбилеегыз белән котлыйбыз. Сез безгә һәрчак үрнәк булып яшисез, йөзегез көләч, күңелегез күтәренке. Сезгә исәнлек, җан тынычлыгы, балалар һәм оныкларыгызның хөрмәтен тоеп яшәргә язсын.

Төсләрнең балкышы дөньяда,
Көз инде киенгән алтыннан.
Караңгы төннәрдә яктыртып,
Күкләрдә йолдызлар кабынган.
Йөзегез нур чәчә җиһанга,
Әйтерсең җирдәге фәрештә.
Без сезгә телибез саулык һәм
Уңышлар башлаган һәр эштә.

Шушы теләкләргә Уфадан Роберт абый Шәрәфиев, Түбән Камадан Мөбарәкшиннар, Зарифуллиннар, Гыйльметдиновлар, Шәрифуллиннар гаиләсе, балалары Илшат, Гөлшат, Чулпан гаиләсе һәм оныклары кушыла.

Язучы фикере

Роботлар заманы

Язучы өчен шартлар бүген бик әллә ни түгел. Ә Американың Джорджия технология институты галимнәре аны тагын да ныграк катлауландырырга уйлаган. Соңгы арада алар язучыны роботка алыштыру мәсьәләләре белән мәшгуль икән. Бу өлкәдә ярыйсы гына уңышка да ирешкәннәр. Нәтиҗәдә бирелгән тема буенча кыска хикәяләр иҗат итә алучы робот барлыкка килгән. Ясалма акыл иясе булган шушы роботка Шәһрезадә дип исем кушканнар. Бу хикәяләрне укып караган кешеләр аларның ярыйсы гына икәнен бәяли.

Эш тәртибе болайрак барган. Шәһрезадә кинога бару һәм адәм талау темасына ике йөзгә якын хикәяне анализлап чыккан һәм шулар нигезендә менә мондыйрак яңа текст барлыкка китергән: «Янына Джон килүгә Салли сискәнеп китте, чөнки ул бик шикле күренә иде. Джон үз кесәсеннән пистолет тартып чыгарды. Һәм аяусыз караш ташлап, аны Саллига төбәде. Салли бик курыкты һәм кычкырып җибәрде. Карлыккан тупас тавыш белән Джон акча таләп итте».

Шәһрезадә үзе анализлаган текстларның мәгънәсен аңламый, бары тик еш кабатлана торган схемаларны барлый, үз «иҗат»ын да шулар нигезендә төзи. Әйтик, әгәр ул берничә авторның текстында кабатлана торган җөмлә төзелеше күрә икән, аларны бик мөһимгә исәпләп, хәтеренә салып куя. Моннан тыш Шәһрезадә вакыйгаларның эзлеклелеген дә таный белә, шуңа күрә аның язганнары мантыйктан читкә тайпылмый.

Ясалма акылның хикәя төзүдәге уңышлары галимнәр өметләнгәнгә караганда да яхшырак килеп чыккан. Алар беренче тәҗрибәләр үткәргән вакытта хикәянең кинога билет алу, залга кереп, үз урынына барып утыру, экранга төбәлү турындагы гадәти җөмләләрдән торуын көткән. Әмма Шәһрезадә графоманнар ысулын кабатламыйча, үз юлын таба алган – кинога баргач, беркадәр сәер шартларда танышып киткән егет белән кыз турында язган. Һәм ул әсәрне кем язганын да белмәгән килеш укыган чит кешеләрнең 83 проценты аны уңышлы дип бәяләгән.

Шәһрезадәнең сәләтен үстерү максатыннан галимнәр фрилансерлардан гади җөмләләрдән торган кыска хикәяләр сатып ала һәм аны роботның хәтеренә сала бара.

Галимнәрнең уңышы шау-шуга да сәбәпче булган. Мондый роботлар язучыларны әдәбияттан кысрыклап чыгара аламы, дигәнрәк бәхәсләр бара. Бу хакта фикерләр төрлечә.

«Алар кулъязманы вакытында тапшыра. Алар иҗат кризисыннан тилмерми. Алар үз әсәрләренең ничек сатылганын белешеп, сәгатьләр буе интернетта утырмый. Робот язучыларның бер генә проблемасы бар – хикәяләре ташка үлчим», – дип көлә The Guardian газетасы.

Галимнәр үзләре иҗат мәсьәләсендә Шәһрезадәнең күпкә йомшаграк булуын билгели. Чөнки ул хисләргә бирелә белми һәм ирония, сарказм, чагыштырулар белән эш итүдән ерак тора. Ләкин анысы – киләчәк эше.

Ә инглиз язучысы Джеймс Брайдл иртәме-соңмы нәфис әдәбият кешеләр иҗаты гына булудан туктаячак дип белдерә: «Робот-язучылар иң катлаулы өлкәләрдә автордаш булып калырга һәм киләчәк вакыйгаларын күзаллауда ярдәм итәргә мөмкин», – дип яза ул The Guardian басмасында.

Роботларның кешедән иң зур аермасы – аларның эшкә сәләте чиксез. Шәһрезадәгә бу гади түгел, ә интерактив хикәяләр язу мөмкинлеге бирә. Икенче төрле әйткәндә, укучының сайлавына бәйле сюжетка корылган әсәр. Вакыйгаларның кызган урынына җиткәч, укучы аның кай юнәлештә үсешен үзе сайларга мөмкин. Әйтик, Гали иртән торды, юынды, чәй эчте һәм көтмәгәндә ишектә кыңгырау шалтырады. Гали ишекне ача һәм… Менә монда сюжет төрле юнәлештә үсәргә мөмкин: анда чәчәкләр тотып сөйгән кызы тора, участок инспекторы тора яки пистолет күтәреп киллер тора. Укучы шуларны үзенә ошаганын сайлап ала да укуын дәвам итә. Интерактив хикәя шул чамарак була инде. Мондый сюжет чатлары буенча эшләү язучы кеше өчен бик авыр, чөнки бер әсәр кысасында ул әллә ничә әсәр уйлап табарга тиеш. Ә роботлар булдыра алырга мөмкин.

Болар барысы да әлегә киләчәк эше булып кала. Язучыларга бүген-иртәгә генә бернинди дә куркыныч янамый. Тыныч йокларга мөмкин.

Марат КӘБИРОВ

ИКЕ КУЛЫНА – ЙӨЗ ЭШ

НУРЛАТТА ЯШӘҮЧЕ ГӨЛСИРӘ СӘЙФУЛЛИНАНЫҢ БЕЛМӘГӘНЕ ЮК

Шөгыль

Нурлат шәһәрендә яшәүче Гөлсирә Сәйфуллинага 70 төрле һөнәр дә аз. Барлык ир эшен дә белә, диләр аның турында. Печәнен дә чаба, диванын да тышлый, кранын да бора, балта, пычкысын да тота. Буш вакытында – таксист. «Эшкә мине «нужа бабай» өйрәтте», – ди ул. Шул вакытта илләр гизәргә дә, спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт таба.

Гөлсирә – Кәкре Тау авылыннан. Кечкенәдән тиктормас була ул: агач, койма, түбә башыннан төшмәгән. Яшьли мотоцикл йөртергә өйрәнгән, көтүгә дә атка атланып чыккан. Кичтән ат караучыдан сорап, бахбайны алып кайта торган булган.

– Мине әтинең кечкенә кыз малае дип йөртәләр иде. Гел аңа ияреп йөри идем. Мотоцикл ватылса, икәү ясадык. Әти авырды, шуңа күрә ир эшенә өйрәтте дип әйтә алмыйм. Күптән вафат инде. Без гаиләдә алты бала. Өч абый да авылдан чыгып киткәч, телисеңме-теләмисеңме, эшкә өйрәнергә туры килде. Абый белән тракторда да йөргәләдем әле. Хәзерге вакытта 84 яшьлек әнине тәрбиялим. Авыл белән Нурлат арасын таптарга туры килә. Әнинең үзен генә калдырмыйм, – ди Гөлсирә.

Авылда үз йортлары белән яшәгәч, кран борырга, су шлангасын алыштырырга яки башкасын эшләргә һаман саен кеше эзләп йөреп булмый. Бер-ике әйтәсең дә өченчесендә үзең эшлисең. Гөлсирә шулай ди. Башкаларның хезмәтенә сокланып карау да җитә аңа. Истә калдыра да ясый, бернинди интернет та кирәкми. Электриканы белмим, дисә дә, розеткаларны үзе алыштыра. Канализация чокырын да чистарта, кыскасы, сантехник та үзе. Сваркага өйрәнмәкче. Эретеп ябыштыру җайланмасы сатып алырга хыяллана. Ишегалдын чапкыч белән үзе чаба. Шөгыльгә өйрәнгәндә, төрле чагы булган анысы. Чалгы игәүләгәндә, кулын җәрәхәтләгәне, чүкеч белән бармагына сукканы да, мотоциклда егылып, «глушитель»гә аягын пешергәне дә… Тик Гөлсирәне болар гына уеннан кире чигендерә алмаган.

– Берәүнең дә миңа: «Нигә ир эшен эшлисең?» – дигәне юк. Ишегалдында эшләгәндә, киресенчә, сокланып китәләр. Ирләр, бабайлар кызыксынып карап тора. Кайберләре, син ирләр эшли белмәгәнне эшлисең, ди. Әти янында мәш килеп үскәнгәме, миндә күбрәк ирләр холкы. Тик күңелем нечкә минем, бөтен кешенең хәсрәтен үземә җыям, – ди ул.

Математиканы мәктәптә яхшы укыган. Кирәк икән, Гөлсирә мунча, йорт төзергә күпме материал кирәклеген дә чутлап бирә ала. Үз мунчасына да кадагына кадәр исәпләгән. Мондый эшләрне бик яратып башкарам, ди. Идәнен дә юа, ашарга да пешерә. Әмма өйгә караганда, ихатада эшләү күбрәк ошый аңа.

– Кулы чүкеч, балта тота белмәгән ирләргә ачуыгыз киләме? – дип сорадык аннан.

– Эшли белмәсә, ачу чыкмый. Кемдер – баш, кемдер кул белән эшли бит. Белми икән, белми инде, нишләтәсең. Ә менә үзе берни белмичә, акыл өйрәтеп торса, ачу чыга, әлбәттә, – ди Гөлсирә.

Тормышта нәрсәдер килеп чыкмады дип уфтанып утырмый. Авырлыкларны ничек булса да җиңәргә тырыша. Мәктәпне тәмамлагач, берничә баллы җитмәү сәбәпле, Казан авыл хуҗалыгы институтына керә алмаган. Аптырап тормый, Мәскәүдә яшәүче абыйсы янына барып, яшелчәчелек буенча училищега укырга керә. Аннан Мәскәү өлкәсендәге Одинцово шәһәрендәге «Заречье» совхозында ике еллап кыяр, помидор, борыч үстерә. Әлеге тәҗрибәнең хәзер дә бакча, теплица эшендә кирәге чыга. Мәскәүдән кайтып, Нурлат шикәр заводына эшкә урнаша. Шуннан соң нефтебазада 12 ел оператор булып эшли. Кыскартуга эләккәч, Казанда диспетчер вазыйфасын башкара. Тик әнисе авырый башлагач, аны тәрбияләргә авылга кайтырга туры килә. Менә инде ул өченче ел – таксист.

– Таксист булып эшләвемә төрлечә карыйлар. Берәүләр сокланып, хөрмәт белән, икенчеләр кызганып… Янәсе, мине тормыш шулкадәр изгән, шуңа күрә шушы эштә тилмерәм. Юк, алай түгел. Әйтеп торам бит, техника күңелемә кечкенәдән якын дип, – ди ул.

Ир эшенә чумып, хатын-кыз булуын оныта дип уйлый күрмәгез тагын. Күңелсез яшәми, узган ел ике мәртәбә Кавказга барып кайткан. Мисыр, Кипрда да булганы бар. Чаңгы шуа, бассейнга йөзәргә йөри.

– Мин тыйнаклыкны яратам. Артык җете итеп бизәнмим. Тырнак ясатырга салонга ике мәртәбә барганым бар. Чөнки чит илләргә матур итеп барасы килде. Авылда кулда болгарка яки башка эш коралы булганда, тырнак кайгысы түгел. Тик тырнаклар һәрвакыт каралган. Холкым ирләрнеке кебек булса да, беркайчан да үземнең хатын-кыз икәнлегемне онытмыйм, – ди шат күңелле Гөлсирә.

Менә шундый булдыклы Гөлсирә ялгыз. Кияүгә чыгып караган, тик гаилә тормышы барып чыкмаган. Хәзергә ул әни хакы дип яши.

Сәрия МИФТАХОВА

Язмышлар ярында

ИҢНЕ ИҢГӘ ТЕРӘП…

Гаилә тормышы шактый катлаулы, тикмәгә генә аны кечкенә бер дәүләт дип йөртмиләрдер. Сау-сәламәт ике кеше тигез итеп тартканда да гаилә йөге таманга туры килә. Шуңа күрә дә сәламәтлекләре чикле ике кешенең парлашып, үз өсләренә шундый йөк алулары икеләтә сокландыра. Үтә тәвәккәлләр генә сәләтледер мондый адымга.

«Безнең «Фикердәш» клубында гына да андыйлар дистәгә якын», – ди үзе кебек мөмкинлекләре чиклеләрне бергә туплау өчен әлеге клубны оештыручы Чулпан Габделганиева. Балтач районының Кариле авылы кызы ул. Күпләрне төрле яклап сокландыра: кул эшләре остасы – пешекче, чигүче, уенчыклар бәйләүче, шагыйрә – берничә китап авторы, шашка буенча дөнья чемпионы, спорт остасы, шәп оештыручы… – аның турында без шактый яздык.

– Әлеге клубны оештыруга быел унсигез ел булды. Шул уңайдан үткәрелгән бәйрәмдә әнә шундый матур гаиләләребез бүләкләнде. Берсеннән-берсе булдыклы, искиткеч уңган-булган егет-кызларыбыз алар барысы да, – ди ул.

Чулпан җайлап кына һәр гаилә белән таныштыра. Алар арасында безнең укучыларыбызга таныш язмышлылар байтак. Күбесе турында язганбыз икән инде.

Бүген Балтачта яшәүче Ләйсән һәм Марс Сәләхетдиновлар «Фикердәш»нең иң актив пары икән. Моннан ун еллап элек гаилә корганнар. Марс спортта бик актив, кул көрәше, җиңел атлетика ярышларында җиңүләре, уңышлары шактый. Мәскәүдәге спорт академиясен дә тәмамлаган булган, сәламәтлеге какшап кына үз белгечлеге буенча эшләп китә алмаган. «Бәйрәмнәребезгә парлап киләләр, ярышларда яратып катнашалар», – ди алар турында Чулпан.

Чепья кызы Гөлназ һәм Куныр егете Расил турында да, сокланып, берничә тапкыр яздык без. Икесе дә язмыш сынауларына бирешмичә, бер-бер артлы авырлыкларны җиңә барган Гафиуллиннарның бүген, тормышларын ямьгә төреп, кызлары үсеп килә.

Балтачта яшәүче Руфия һәм Рөстәм Әүхәдиевләрнең икесендә – бер үк диагноз, балачактан ДЦП белән көрәшәләр. Бәлки шуңадыр да алар бер-берсен башкалардан ныграк аңлый. Шушы аңлау аларга бер-берсенә һәрчак терәк-таяныч булырга ярдәм итәдер дә инде.

Нөнәгәр кызы Зөлфиянең кул эшләренә осталыгы турында да сокланып язган идек. Аннан соң аның бер бәйгегә баргач, Руслан исемле егет белән танышуы, гаилә корулары, уллары Салават туу турында да яздык. Үткән еллар эчендә Сәйдәшевләрнең кызлары Алсу туган, инде бакчага йөри икән. «Әниләре Мәүлия апа белән бергә, күп итеп мал-туар асрап, бик тырышып көн күрәләр. Руслан каравылга эшкә дә урнашкан, бәйрәмнәргә парлап килергә дә вакыт таба алар», – ди Чулпан.

– Түнтәрдән бик тырыш, актив кызыбыз Энҗе бар иде әле. Берничә ел элек мөмкинлекләре чикле кызлар арасындагы республика бәйгесендә катнашып, җиңүчеләрнең берсе булды. Әлеге чараны телевизордан күрсәткәндә күрше Саба районы егете Азат аңа гашыйк була. Җиде ел инде Сабада, төп йортта яшиләр, бер ул, бер кыз үстерәләр, бәйрәмнәргә килә алмасалар да, безнең белән гел элемтәдә алар, – дип, тагын бер матур пар белән таныштыра Чулпан. – Рәзинә белән Руслан Садретдиновлар исә – безнең клубта танышып, гаилә корган парыбыз. Алар да төп йортта яши, ул үстерәләр. Балтач кызы Әдилә белән Борнак егете Алмаз да гаилә корганчы ук безнең клубка йөрделәр, шушы танышлык – дуслыкка, аннан мәхәббәткә әйләнде дип беләм. Үзләре генә аерым фатирда яшиләр, бик тырышып, матур итеп көн күрәләр. Кул көрәше ярышларына даими йөргән Марселебез исә үзенең тиң ярын әнә шундый ярышларның берсендә очрата. Бу гаилә дә Балтачта яши, ике бала үстерә. Гаилә корып, балалар үстергән парларның кайберләре үзләрен тулысынча гаиләләренә багышлады, без үткәргән чараларга сирәгрәк килә, без аларга үпкәләмибез, аңлыйбыз, үзләре, гаиләләре әйбәт кенә булсын, – ди Чулпан.

Без дә шул теләктә. Иңнәрен иңгә терәп, гомер буе бер-берсенә таяныч булып яшәргә язсын.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 354

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+